КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 сентябрь г.Казань № 874

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 май, 360 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 май, 360 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктның дүртенче абзацында «банкротлык» сүзен төшереп калдырырга, «тормаска» сүзеннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булырга» сүзләрен өстәргә;

8 нче пунктның алтынчы абзацында «яки банкротлык» сүзен төшереп калдырырга, «тормавын» сүзеннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләрен өстәргә;

14 нче пунктның өченче абзацына «максатчан билгеләнеше,» сүзләреннән соң «субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсе,» сүзләрен өстәргә;

15 нче пунктта:

беренче абзацта «Чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидия күләме» сүзләрен «Субсидия күләме (С)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидияләр алучылар тарафыннан субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылганда;

субсидиядән файдалану турындагы хисап билгеләнгән вакытта тапшырылмаганда;

субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылганда;

субсидия акчасыннан файдалану бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга туры килмәгәндә;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә.

Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле $19^1$ нче пункт өстәргә:

«$19^1$. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләү тора.

Субсидия алучы баш эш итүчегә, субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 сентябрь, 874 нче карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасының электр энергетикасын үстерү схемасын һәм программасын эшләүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап

Юридик зат исеме: ________________________

| Т/с | Килешү предметы, документның реквизитлары | Финанслау лимиты | Бюджеттан финансланды (арта бара торган йомгак белән) | Касса чыгымы (арта бара торган йомгак белән) | Хисап датасына үзләштерелмәгән акча | Раслый торган документлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | | | | | | |
| … | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _______________ _____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы _____________ ________________________________ ______________
(вазыйфасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (телефоны)

20__ ел, «__»________

---